| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.03.2019 п.г.т.Алексеевское № 101

**“Алексеевск муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 3 сентябрь, 2018 ел, 275 нче карарына үзгәрешләр кертү турында**

Федераль закон таләпләренә туры китерү максатында“Алексеевск муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 3 сентябрь, 2018 ел, 275 нче карарына үзгәрешләр кертергә

**карар бирәм:**

1. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентында бушлай сроклы файдалануга (9 нчы Кушымта):

- 2 нче пунктның 11 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: бакчачыклык яки яшелчәчелек коммерциячел булмаган ширкәтләргә биш елдан да кимрәк булмаган срокка”.

2. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентында арендага торглар үткәрмичә файдалануга (8 нче Кушымта):

- 3 нче пунктның 2 нче пунктчасында “яки дача хуҗалыгы” дигән сүзләрне алып ташларга;

- 39.6нчы маддәнең 2 нче пункты 7 һәм 8 нче пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

7) бакчачыклык яки яшелчәчелек коммерциячел булмаган ширкәтләргә бирелгән җир кишәрлекләреннән барлыкка килгән (гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләреннән башка) бакчачыклык яки яшелчәчелек җир кишәрлеген шундый ширкәтләр әгъзаларына;

8) гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачыклык яки яшел чәчелек алып бара торган территория чикләрендә урнашкан гомуми файдаланудагы җир кишәрлеге булып торучы әйләнештә чикләнгән җир кишәрлеге арендаторлар янында бик күп кешеләр булган андый территория чикләрендә бакчачыклык яки яшелчәчелек хокукына ия булып торучы гражданнарга (әгәр күрсәтелгән җир кишәрлеген бирү зарурлыгы андый территория чикләрендә гомуми файдаланудагы милеккә идарә итүне тормышка ашыручы бакчачыклык яки яшелчәчелек коммерциячел булмаган ширкәте әгъзаларының гомуми җыелышы карары белән алдан каралган булса);

8.1 нче пунктчаны түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

8.1) шәхси торак төзелеше максатында территорияне комплексы үзләштерү өчен юридик затка бирелгән әйләнештә чикләнгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм гомуми файдаланудагы җир кишәрлеге булып торучы җир кишәрлеген андый юридик затка”.

3. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында милек (10 нчы кушымта):

39.5 маддәнең 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3) территорияне межалау проекты нигезендә барлыкка килгән һәм гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачыклык яки яшел чәчелек алып бара торган территория чикләрендә урнашкан гомуми файдаланудагы җир кишәрлеге булып торучы җир кишәрлеген андый территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләре булып торучы кешеләрнең уртак өлеш милкенә әлеге кишәрлекләр мәйданына пропорциональ рәвештә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Рәсми сайтында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлеек итүне Алексеевск муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасырәисе М.Р.Гайсинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**